СОВЕТ ЦИПЬИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЧЕПЬЯ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«28» октябрь 2022 ел №70

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Чепья авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым җыю һәм файдалану тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы № 131-ФЗ Федераль законның 56 статьясы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Чепья авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Чепья авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1.Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлеге территориясендә үзара салым җыю һәм гражданнарның үзара салымы тәртибе турындагы Чепья авыл җирлеге Советының 11.04.2014 елгы № 110нчы карары белән расланган ( 10.11.2017 ел, №90 редакциясендә) нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 5.1 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

яшәү урыны буенча теркәлгән 18 яшькә җиткән барлык гражданнардан; 50 процент күләмендә ташлама каралган 1 төркем инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, 80 яшьтән югары өлкән пенсионерлардан, балигъ булмаган балалар тәрбияләүче тулы булмаган гаиләләрдән, Россия Федерациясе кораллы көчләренә мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш; үзара салым акчалары җирле референдумда кабул ителгән карарларның нәтиҗәләрен игълан иткәннән соң өч ай эчендә җирлек башкарма комитетының банк реквизитларын, шулай ук түләү тәртибе турында мәгълүматны үз эченә алган Башкарма комитет белдерүе нигезендә җыела.

2.Әлеге карар имзаланган көннән үз көченә керә.

3.Әлеге карарны районның baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Чепья авыл җирлеге башлыгы А.Г.Нотфуллин